# *Бәйлек сүзләр*
# *Послеложные слова*

# ы, е хәрефләренең дөрес язылышын искә төшерик

Бол_т, йолд_з,
төсл_, дөр_с,
бор_н, чок_р, сөлг_,
көчл_, бор_ч.

В татарском языке большую группу **послеложных слов** составляют имена, выражающие пространственные и временные отношения. Употребляясь в пространственных падежах, они являются своеобразным средством связи. Это такие слова, как *ас* (низ), *өс* (верх), *урта* (середина), *баш* (начало), *як* (сторона), *ян* (бок), *арт* (зад), *ал* (перед), *төп* (низ, дно), *ара* (промежуток), *каршы* (перед, навстречу), *буй* (вдоль) и т.д. Они употребляются в трех падежах: дательном, исходном, местно-временном (часто с аффиксами принадлежности третьего лица).

янымда

Минем    артымда   ..... утыра.

каршымда

*Алар III заттагы кушымчаларны ялгыйлар.*
*Они обычно присоединяют аффиксы принадлежности III лица* – **ы,-е, -сы,-се**

Аст..., өст..., , ян..., як(г)... алд..., арт..., баш..., эч..., , урта...

*Асты, өсте, яны,*
*ягы, алды,*

*арты, башы, эче,*

*уртасы*

# Рәсемнәргә карап әйтегез.
# Китап кайда ята ?






Барлык бәйлек сүзләргә нинди сорау куеп була?

Килешен билгеләгез.

Кушымчаларны әйтегез.

**У.в.к.**

***(кайда?-где?)***

***-нда/-ндә***

*янына –к (столу)*

*өстәл* *өстенә- на (стол)*

*астына-под (стол)*

Бәйлек сүзләргә нинди сорау куеп була?

Килешен билгеләгез.

Кушымчаларны әйтегез.

**Ю.к**

**(кая?-куда?)**

**-на/-нә**

| | |
|---|---|
| | ***яныннан (от стола)*** |
| | ***өстеннән (со стола)*** |
| ***өстәл*** | ***алдыннан (перед столом)*** |
| | ***астыннан (из-под стола)*** |

Бәйлек сүзләргә нинди сорау куеп була?

Килешен билгеләгез.

Кушымчаларны әйтегез.

**Ч.к.**

***(кайдан?-откуда?)***

***-ннан/-ннән***

# Нәтиҗә яса:

1) Бәйлек сүзләр (послеложные слова) нинди сорауларга җавап бирә?
2) Кайсы килешләрдә килә?
3) Бәйлек сүзләр исемнең алдыннан киләме, әллә артыннанмы?

## 3нче күнегү. Нокталар урынына тиешле кушымчаларны куеп язарга.

- Табын уртасы... матур вазада чәчәкләр. Ул тәрәзә алды... басып тора. Шәһәр урасы... тимер юл үтә. Күл яны... камышлар үсә. Мәктәп алды... чәчәкләр утырттык. Парта өсте... китапларны алды.

# физкультминутка

- Без әле бераз ардык,
Ял итәргә уйладык:
Башны иябез алга,
Ә аннары-артка.
Уңга-сулга борабыз,
Аннан карап торабыз.
Иң өстен сикертәбез,
Кулларны биетәбез.
Бер алга, бер артка сузы
Күңелле ял итәбез.



Текст белән эш.

Табын янында.

# Сүзлек эше:

табын-стол

валчыклар-крошки

аунап ята иде- валялись

***Текстны укыгыз. Бәйлек сүзләр булган җөмләләрне табыгыз, бәйлек сүзләргә сорау куегыз.***

Табын янында.

Мин кичә бер гаиләгә кунакка бардым.Табын янына хуҗа малае Саша да утырды. Өстәл өстендә зур савыт белән салат тора. Саша салатны үз янына куйды һәм тиз-тиз ашый башлады. Хуҗабикә безгә аш бирде: башта миңа, аннан соң Сашага. Саша башкаларны көтмәде, ашны ашый да башлады. Ул авызын чапылдатып, сөйләшә-сөйләшә ашады. Аштан итне кулы белән алды да өстәлгә куйды.Десертка алма бирделәр. Хуҗабикә малае иң зур алманы алды да табын яныннан китте. Өстәл өсте бик пычрак калды: анда ит һәм ипи валчыклары аунап ята иде.

- *Сашаның табын янында үз –үзен тотышы сезгә ошадымы?*

- *Саша нинди малай?*



***Сез Сашага биргән киңәшләр белән килешәсезме?***

***- Ашар алдыннан кулларыңны ю.***
***- Өстәл янында тәртипле утыр.***
***- Табын янында сөйләшмә,көлеп утырма.***
***- Табын яныннан киткәндә,рәхмәт әйтергә кирәк.***

# Өй эше.

- 1. Бәйлек сүзләрне ятларга.
- 2. 101нче бит 6нчы күнегү.

**Йомгаклау.**

- Нинди бәйлек сүзләр беләсез?
- Бу бәйлек сүзләрне нинди килешләрдә кулландык?
- Алар нинди сорауларга җавап бирде?